**ГЛАВА
ЛЕНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 19 нчы ноябре №6

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында гражданнар җыелышы нәтиҗәләре турында» 2025 елның 18 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыелышы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында гражданнар җыелышын билгеләү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Ленино авылына гражданнар җыелышы нәтиҗәләре турында» 2025 елның 18 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыелышы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча үзара салым Җыенын 2025 елның 1 декабрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Гражданнар Җыенының 2025 елның 18 октябрендәге 1 номерлы карарына карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары белән «Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә» сүзләре белән үзгәрешләр кертергә ризамы».

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авылындагы Җиңүнең 40 еллыгы урамындагы 32 нче йорт янындагы мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Бу карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино
авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина

СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ